РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20 ноябрь, 2020 ел Кукмара ш. № 28

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2020 елның 7 маендагы 283 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы боерыгына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы һәм 821-р номерлы күрсәтмәләренә кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 7 маендагы 283 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль район Советының карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм чаралары турында»;

2. Преамбулада «эшмәкәрлек» сүзеннән соң «, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар» сүзләрен өстәргә;

3. Карарның 1 пунктында «эшмәкәрлек» сүзеннән соң «, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар» сүзләрен өстәргә;

4. Карарның 2 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә гавами милекне арендалаучылар – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек

субъектлары, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә гавами милекне арендалаучылар – социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар Палатага Тәртип нигезендә өстәмә килешү төзү турында гариза белән мөрәҗәгать итү урынына, Палатага 2020 елга каралган аренда түләвен «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең әлеге Федераль законның күрсәтелгән статьясы нигезендә кабул ителгән хокукый актында каралган тәртиптә һәм шартларда кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү һәм (яки) аренда түләве күләмен үзгәртү турында өстәмә килешү төзү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы, дип билгеләргә.»;

5. Карар белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору, аренда түләүләрен түләүдән азат итү һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә түләүне кичектереп тору Тәртибендә (алга таба – Тәртип):

4.1. Исемендә «эшмәкәрлек» сүзеннән соң «, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар өчен» сүзләрен өстәргә;

4.2. Тәртипнең 1 пунктында «эшмәкәрлек» сүзеннән соң «, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар өчен» сүзләрен өстәргә;

4.3. Тәртипнең 2 пунктында:

- түбәндәге эчтәлекле 2.5 пункт белән тулыландырырга:

«2.5. Социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар − 670-р номерлы Күрсәтмәнең 2 (1) пунктында күрсәтелгән (күрсәтелгән) реестрга (реестрларга) кертелгән оешмалар;

- 2.5 пунктчасын 2.6 пунктчасы дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Аренда түләвен кичектереп тору турында килешү – Палата һәм КУЭ субъекты (социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма) арасында 98-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә төзелгән 2020 елда каралган аренда түләвен түләүне кичектереп торуны күздә тота торган өстәмә килешү;»;

- 2.6 пунктчасын 2.7 пунктчасы дип санарга һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Аренда түләве күләмен үзгәртү турында килешү − Палата һәм КУЭ субъекты (социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма) арасында 98-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә төзелгән аренда түләве күләмен үзгәртү турында өстәмә килешү;»;

- 2.7 пунктчасын 2.8 пунктчасы дип санарга һәм аны ктүбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Өстәмә килешү – КУЭ субъекты (социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма) тәкъдим иткән, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңгармаган вакытка аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору (аренда түләвен кичектереп тору һәм аренда түләве күләмен үзгәртү турындагы

килешүдән тыш) турында Палата һәм арендатор-КУЭ субъекты (иҗтимагый юнәлешле коммерциячел булмаган оешма) арасында төзелә торган гавами мөлкәтне арендалау шартнамәсенә өстәмә килешү, Палата һәм реклама конструкциясе хуҗасы-КУЭ субъекты арасында төзелә торган реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм файдалану шартнамәсенә мондый реклама конструкциясе хуҗасы тәкъдим иткән, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңармаган вакытка өстәмә килешү).»;

4.4. Тәртипнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Гавами милек арендаторы булган КУЭ субъекты Палатага 2020 елның 1 апреленнән 1 октябренә кадәр исәпләнгән аренда түләүләрен түләүне кичектерү турында, аларга үзе тәкъдим иткән кичектереп тору, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңгармаган вакытын күрсәтеп, гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Гавами мөлкәт арендаторы булган һәм Тәртип нигезендә аренда түләүләрен түләүдән азат ителгән КУЭ субъекты Палатага 2020 елның 1 июленнән 1 октябренә кадәр исәпләнгән аренда түләүләрен түләүне кичектерү турында, аларга тәкъдим ителгән кичектереп тору, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңармаган вакытын күрсәтеп, гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Гавами мөлкәт арендаторы булган КУЭ субъекты, 670-р номерлы күрсәтмәнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында каралган очракларда, 2020 елның 1 апреленнән 1 июленә кадәр исәпләнгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү хокукына ия. Әлеге хокукны гамәлгә ашыру өчен, гавами мөлкәт арендаторы булган КУЭ субъекты Палатага аренда түләүләрен түләүдән азат итү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.»;

4.5. Тәртипне түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункты белән тулыландырырга:

«$3^1$. Гавами мөлкәт арендаторы булган социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма Палатага 2020 елның 1 июленнән 1 октябренә кадәр исәпләнгән аренда түләүләрен түләүне кичектерү турында, аларга үзе тәкъдим иткән кичектереп тору, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңармаган вакытын күрсәтеп, гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Гавами мөлкәт арендаторы булып торучы һәм Тәртип нигезендә аренда түләүләрен түләүдән азат ителгән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма Палатага 2020 елның 1 июленнән 1 октябренә кадәр исәпләнгән аренда түләүләрен түләүне кичектерү турында, аларга үзе тәкъдим иткән кичектереп тору, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңармаган вакытын күрсәтеп, гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Гавами мөлкәт арендаторы булган социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма, 670-р номерлы Күрсәтмәнең 2 (1) пунктының беренче абзацында каралган очракларда, 2020 елның 1 апреленнән 1 июленә кадәр исәпләнгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү хокукына ия. Әлеге хокукны гамәлгә ашыру өчен, гавами мөлкәт арендаторы булган социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма Палатага аренда түләүләрен түләүдән азат итү турында гариза белән мөрәҗәгать итә»;

4.6. Тәртипнең 4 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян

итәргә:

«4. 2020 елның 1 июленнән 1 октябренә кадәр (2020 елның 1 июленнән 1 октябренә кадәрге чорда) исәпләнгән аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору түбәндәге барлык шартлар булганда бирелә:»;

4.7. Тәртипнең 5 пунктын үз көчен югалткан дип таныргa;

4.8. Тәртипнең 6 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясе хуҗасы булган һәм Палата белән реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзегән КУЭ субъекты Палатага әлеге шартанмә нигезендә 2020 елның 1 апреленнән 1 октябренә кадәр исәпләнгән реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүне кичектерү турында, аларга үзе тәкъдим иткән кичектереп тору, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңармаган вакытын күрсәтеп, гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.»;

4.9. Тәртипнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Тәртипнең 3, $3^1$ һәм 6 пунктларында каралган гаризаларда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

- гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта), яшәү урыны һәм гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ реквизитлары, шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында шәхси эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу турындагы язманың дәүләт номеры (шәхси эшмәкәр өчен)

- юридик затның исеме һәм урнашу урыны, юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы язманың дәүләт теркәү номеры (юридик зат өчен);

- социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма статусын раслаучы белешмәләр (социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар өчен);

- салым түләүченең идентификация номеры;

- гариза бирүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы;

- аренда түләүләре исәпләнгән, реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләр исәпләнгән һәм гариза бирүче аларга карата түләүне кичектереп торуны (түләүдән азат итүне) сорый торган айлар (чор), шул ук вакытта гаризада күрсәтелгән айлар (гаризада күрсәтелгән чор) 2020 елның 1 апреленнән 1 октябренә кадәр вакыт чикләрендә булырга тиеш;

- аренда түләүләрен түләүне кичектерүнең тәкъдим ителә торган вакыты, реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләрне кичектереп тору вакыты (аренда түләүләрен кичектереп тору һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен исәпләнгән түләүләрне кичектереп тору турында гаризаларда), ләкин 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча.

Тәртипнең 3 һәм $3^1$ пунктларында каралган гаризаларда, моннан тыш, түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

- гариза бирүче аренда түләвен кичектереп тору турында килешү, аренда

түләве күләмен үзгәртү турында килешү төзү мөмкинлеген регламентлаучы 98-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре белән һәм күрсәтелгән Федераль законның 19 статьясындагы 1 өлешен үтәү йөзеннән кабул ителгән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый акты белән таныШты;

- гариза бирүче, 98-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә аның белән өстәмә килешү төзегән очракта, өстәмә килешүдә каралган ярдәм чараларын алу хокукын югалта.»;

4.10. Тәртипнең 8 пунктындагы алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаризаның тәкъдим ителгән формасы Тәртипкә Кушымтада тәкъдим ителгән.»;

4.11. Тәртипнең 9 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- түбәндәге очракларның берсе генә булса да, гариза бирүчегә гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны (мондыйлары булган очракта) кире кайтара: а) гариза Тәртипнең 7 пункты таләпләренә туры килми; б) электрон төрдәге гариза һәм аңа кушып бирелгән документлар (мондыйлары булган очракта) Тәртипнең 8 пунктындагы бишенче абзацы таләпләренә туры килми; в) гариза бирүче белән Палата арасында гавами мөлкәтне арендалау шартнамәсе юк (төзелмәгән) (аренда түләүләрен кичектереп тору, аренда түләүләрен түләүдән азат итү турында гариза биргәндә); г) гариза бирүче белән Палата арасында реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә килешү юк (төзелмәгән) (реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен исәпләнгән түләүне кичектереп тору турында гариза биргәндә); д) гариза 2020 елның 31 декабреннән соң бирелгән;»;

4.12. 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Гавами милекне арендалау шартнамәсенә өстәмә килешүдә түбәндәгеләр турында шартлар булырга тиеш:

- әлеге килешү якларының хокуклары һәм бурычлары түбәндәге очракларның берсе генә булса да туктатылган дип санала: а) Палата һәм арендатор-КУЭ субъекты (арендатор-социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма) арасында аренда түләвен кичектереп тору турында килешү һәм (яки) аренда түләве күләмен үзгәртү турында килешү төзегәндә; б) Тәртипнең 8 пунктындагы бишенче абзацында каралган срокта Палатага гариза һәм аңа кушып бирелгән документлар (андыйлар булганда) кәгазьдә тапшырылмаганда; в) КУЭ субъекты (социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма) тарафыннан имзаланган әлеге килешү Палатага 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә кертелгән югары әзерлек режимы (гадәттән тыш хәл режимы) тәмамланган көннән алып утыз көн эчендә кермәгәндә;

- кичектерелгән аренда түләве буенча бурыч этаплап түләнә, әмма аена бер тапкырдан да ешрак түгел, күләме аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмый торган тигез түләүләр белән;

- әлеге килешү нигезендә кичектереп тору (түләүдән азат итү) бирелгән аренда түләүләре законнарда һәм аренда шартнамәләрендә каралган тәртиптә

(кичектерү бирүне (түләүдән азат итүне) исәпкә алмыйча) кертелергә (яңадан торгызылырга) тиеш), әгәр аренда түләвен кичектереп тору (түләүдән азат итү) турында килешүдә һәм (яисә) аренда түләве күләмен үзгәртү турында килешүдә башкасы каралмаган булса (әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән очракларның берсе генә булган очракта да);

- гавами мөлкәт арендаторы, гавами милекне арендалау килешүен вакытыннан алда өзгән очракта, кичектерелгән түләүләрне вакытыннан алда кертергә бурычлы.»;

4.13. Тәртипнең 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Төзү датасына бәйсез рәвештә, өстәмә килешүдә, КУЭ субъекты (социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма) гаризасында күрсәтелгән айлар (чор) өчен, әлеге айлар (чор) 2020 елның 1 апреленнән 1 октябренә кадәр чор чикләрендә булган очракта, аларга карата кичектереп тору (түләүдән азат итү) бирелә торган аренда түләүләре, аларга карата кичектерү бирелгән реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләр булырга тиеш.»;

4.14. Тәртипкә Кушымтаны яңа кушымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итәргә.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2020 елның «20» ноябрендәге 28 номерлы карарына Кушымта

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар өчен аренда түләүләрен түләүне кичектереп торуны бирү, аренда түләүләрен түләүдән азат итү һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләрне кичектереп тору Тәртибенә кушымта

Арендаторлардан-кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалардан, реклама конструкцияләре хуҗалары-кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан гаризаның тәкъдим ителә торган формасы

Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир: мөнәсәбәтләре палатасы рәисе
И.Г. Закировка

кемнән________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

_____________________________________________
гариза бирүче-шәхси эшмәкәрләр өчен;
_____________________________________________
юридик затның тулы исеме

_____________________________________________
гариза бирүче-юридик затлар өчен
_____________________________________________
яшәү урыны адресы (гариза бирүчеләр-шәхси эшмәкәрләр өчен); урнашу урыны адресы (гариза бирүчеләр-юридик затлар өчен):
_____________________________________________

_____________________________________________;
салым түләүченең идентификацион номеры (ИНН): _______________________________________
шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрында шәхси эшмәкәрне дәүләт теркәвенә алу турындагы язманың дәүләт теркәү номеры/ юридик затларның бердәм дәүләт реестрында юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы язманың дәүләт теркәү номеры:
_____________________________________________

шәхесне раслаучы документ реквизитлары (гариза бирүче – шәхси эшмәкәрләр өчен): документ исеме:

_____________________________________________;
документ реквизитлары (серия, номер; бирү датасы; документ биргән орган турында белешмәләр):
_____________________________________________
_____________________________________________
гариза бирүче белән элемтә өчен почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы:
_____________________________________________
_____________________________________________

Аренда түләүләрен кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү төзү турында, аренда түләүләрен түләүдән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешү төзү турында, реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен исәпләнгән түләүләрне түләүне кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү төзү турында
гариза[1]

_____________________________________________
(гариза бирүчеләр-шәхси эшмәкәрләр өчен фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта);

_____________________________________________
юридик зат исеме – гариза бирүче-юридик затлар өчен)

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары реестрына кертелгән, кайсы категориягә кердә
_____________________________________________ 1
(кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты категориясе)

реестрга кертелгән
_____________________________________________
((Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы күрсәтмәсенең 2 (1) пунктында
_____________________________________________
күрсәтелгән реестрның (реестрларның) атамасы;
_____________________________________________
«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә гариза бирүче кертелгән реестр урнаштырылган
_____________________________________________ 2
вәкаләтле органның рәсми сайтына сылтамалар; реестрдан позиция номеры

һәм шартнамә нигезендә
_____________________________________________
(шартнамә исеме; шартнамә реквизитлары)
арендатор булып тора
_____________________________________________
(аренда мөлкәте турында белешмәләр: исеме, адресы, кадастр (яки шартлы) номеры)
_____________________________________________

Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән төзелгән килешү нигезендә реклама конструкциясе хуҗасы
_____________________________________________ 3
(шартнамә исеме; шартнамә реквизитлары)

Бәян ителгәннәрдән чыгып һәм «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга, кече һәм урта

[1] Гариза бирүче-кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты тарафыннан тутырыла.
[2] Гариза бирүче-социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешма тарафыннан тутырыла.
[3] Кирәкмәгәнне сызып ташларга (төшереп калдырырга).

эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү чаралары турында» 2020 елның 7 маендагы 283 номерлы Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының карары нигезендә

**ҮТЕНӘМ:**

Төзергә
_______________________________________________________________________________
(гариза бирүчеләр-шәхси эшмәкәрләр өчен фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта);

_______________________________________________________________________________
гариза бирүче-юридик зат өчен - юридик зат атамасы)

югарыда күрсәтелгән аренда килешүе буенча аренда түләүләрен кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү

_______________________________________________________________________________
(2020 елның 1 апреленнән 1 октябренә кадәр чорга керә торган айлар (ай))

вакытка кадәр_____________________________________________________________
(тәкъдим ителгән көн, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча)

югарыда күрсәтелгән аренда шартнамәсе буенча аренда түләвеннән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешү

_______________________________________________________________________________
(2020 елның 1 апреленнән 1 июленә кадәр чорга керә торган айлар (ай))

хисапланган түләүләрне кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү
_______________________________________________________________________________
(2020 елның 1 апреленнән 1 октябренә кадәр чорга керә торган айлар (ай))

реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә югарыда күрсәтелгән килешү буенча реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен исәпләнгән түләүләрне кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү,
вакытка кадәр _____________________________________________________________[4].
(тәкъдим ителгән көн, әмма 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча)

_______________________________________________________________________________
(гариза бирүчеләр-шәхси эшмәкәрләр өчен фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта);

_______________________________________________________________________________
гариза бирүче-юридик зат өчен - юридик зат атамасы)

2020 елда каралган аренда түләвен кичектереп торуны һәм аренда түләвен киметү мөмкинлеген күздә тоткан өстәмә килешү төзү мөмкинлеген регламентлый торган «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм юк итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәсе турында һәм «Күчемсез милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләү шартларына һәм срокларына таләпләрне билгеләү турында» 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары турында билгеле».

_______________________________________________________________________________
(гариза бирүчеләр-шәхси эшмәкәрләр өчен фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы булган очракта);

_______________________________________________________________________________
гариза бирүче-юридик зат өчен - юридик зат атамасы)

«Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә аның белән өстәмә килешү төзелгән очракта, «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә социаль

---

[4] Кирәкмәгәнне сызып ташларга (төшереп калдырырга).

юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль район Советының 2020 елның 7 маендагы 283 номерлы карары нигезендә төзелгән өстәмә килешүдә каралган ярдәм чараларын алу хокукы» туктатылачак дип ризалаша, әгәр «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм юк итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы нигезендә төзелгән өстәмә килешүдә башкасы каралмаган булса».

Шәхси мәгълүматларны (әлеге гаризада күрсәтелгән һәм аңа кушып бирелгән документларда/документларның күчермәләрендә күрсәтелгән фамилия, исем, әтисенең исеме, яшәү адресы, паспорт мәгълүматлары һәм башка персональ мәгълүматлар) эшкәртүгә, шул исәптән әлеге гаризаны карау һәм хәл итү максатларында дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә әлеге мәгълүматларны тапшыруга, ягъни, автоматлаштыру чараларын кулланып яки шәхси мәгълүматлар белән мондый чараларны кулланмыйча башкарыла торган теләсә кайсы гамәлне (операцияләрне) яки гамәлләрнең (операцияләрнең) җыелмасын кылуга, шәхси мәгълүматларны җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), алу, куллану, тапшыру (тарату, бирү, керү), зарарсызландыру, блоклау, бетерү, юк итүне дә кертеп,ризалык белдерәм. Әлеге килешүнең гамәлдә булу вакыты: сроксыз. Әлеге килешүне кире алу ысулы: шәхси эшмәкәр (шәхси эшмәкәрнең вәкаләтле вәкиле) тарафыннан имзаланган белдерү кәгазе (извещение) (хәбәрнамә/уведомление).[5]

Кушымта:
1. ________________________________________________;
2. ________________________________________________;
3. ________________________________________________;
4. ________________________________________________.

Гариза бирүчедән:

____________________/_____________________/
(имза) (фамилия, инициаллар)
М.У.[6]

«___»_______________2020 ел».

[5] Әлеге абзац шәхси эшмәкәр бирә торган яки шәхси эшмәкәр исеменнән бирелә торган гариза текстына кертелә.
[6] Мөһер урыны; мөһере булган юридик затлар тарафыннан сугыла.